**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 12 март № 147

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 31 декабрь, 1103 нче карары белән расланган Идел буе федераль округында һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең һәркем файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Идел буе федераль округында һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең һәркем файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1103 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 сентябрь, 649 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Идел буе федераль округында һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең һәркем файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

бу Тәртипкә теркәлгән кушымтаны бу карарга теркәлгән кушымта редакциясендә бәян итәргә.

2. Бу карарның гамәле 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына 2015 елда Идел буе федераль округында һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең һәркем файдаланырлык булуын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр

бирү турында авиайөртүчеләр белән шартнамәләр төзүне тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\147.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 12 март, 147 нче
карарына кушымта

2015 елга Идел буе федераль округы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе субъектлары аэропортларына Татарстан Республикасы аэропортларыннан һава транспорты белән пассажирлар йөртү маршрутлары исемлеге

| Т/с | Һава транспорты белән пассажирлар йөртү маршрутлары | | 1 атнага рейслар ешлыгы | Махсус тарифның иң чик күләме, сум | 1 юнәлештәге 1 рейска Татарстан Республикасы бюджетыннан авиайөртүчегә бирелә торган субсидия күләме, сум |
|---|---|---|---|---|---|
| | шәһәр | шәһәр | | | |
| 1. | Казан | Киров | 7 | 2 821 | 18 638 |
| 2. | Казан | Оренбург | 6 | 4 720 | 35 490 |
| 3. | Казан | Пенза | 5 | 3 310 | 23 342 |
| 4. | Казан | Пермь | 10 | 3 744 | 29 714 |
| 5. | Казан | Самара | 7 | 2 311 | 17 507 |
| 6. | Казан | Саратов | 5 | 3 852 | 30 726 |
| 7. | Түбән Кама | Түбән Новгород | 3 | 4 069 | 29 416 |

_______________________________

F:\KARAR\2015\147-1.docx